ГЛАВА
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.02.2025 Баулы шәһәре №23

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Новозареченск авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 17 статьясы нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы "Новозареченск авылы җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча үткәрүне билгеләргә (алга таба - Проект).

2. Иҗтимагый фикер алышулар проекты инициаторы – Баулы муниципаль районы Башлыгы.

3. Иҗтимагый фикер алышулар уздыруны 2025 елның 11 февраленнән 2025 елның 24 февраленә кадәр билгеләргә.

4. Иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект экспозициясен 2025 елның 11 февралендә ачарга:

4.1. Экспозицияне уздыру урыны:

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Новозареченск авыл җирлеге

Башкарма комитеты бинасында Татарстан Республикасы Баулы районы Новозареченск авыл җирлеге, Вахитов урамы, 15 йорт адресы буенча;

- Николашкино авылы, Совет урамы, 38а йорт адресы буенча урнашкан бинада;

- Измайлово авылы, Беренче Май урамы, 17а адресы буенча урнашкан бинада;

- Дмитриевка авылы, Чапаев урамы, 14а адресы буенча урнашкан бинада;

- Таллыкүль авылы, Вахитов урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан бинада.

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru.

4.2. Экспозицияне карау режимы

-Татарстан Республикасы Баулы районы Новозареченск авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Новозареченск авылы, Вахитов урамы, 15 йорт;

- Николашкино авылы, Совет урамы, 38а йорт адресы буенча урнашкан бинада;

- Измайлово авылы, Беренче Май урамы, 17а адресы буенча урнашкан бинада;

- Дмитриевка авылы, Чапаев урамы, 14а адресы буенча урнашкан бинада;

- Таллыкүль авылы, Вахитов урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан бинада.

Эш көннәрендә Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар Мәскәү вакыты белән 2025 елның 11 февраленнән 2025 елның 24 февраленә кадәр эш көннәрендә, 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертергә хокуклы:

- язма рәвештә җәмәгать тыңлауларын оештыручыга Баулы шәһәре, Куйбышев ур., 20 йорт, 101 каб. адресы буенча;

- электрон почта аша Bauly.arch@mail.ru.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетын (алга таба - иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы) билгеләргә.

7. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәр итүне Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлегенең Новозареченск авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль

районының «Интернет» челтәрендәге сайтында www.Bavly.tatarstan.ru бастырып чыгарырга;

7.3. Татарстан Республикасы Баулы районының Новозареченск авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында 2025 елның 11 февраленнән 2025 елның 24 февраленә кадәр, Мәскәү вакыты белән эш көннәрендә 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы www.bavly.tatarstan.ru сайтында экспозицияләр оештырырга;

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы И.И. Гозәеров